СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
15.12.2015

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
№ 39

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре вәкаләтләренең бер өлешен җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе башлыгы Д.А.Бечинның Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләренең вәкиллекле органнары инициативасы турында, “Зеленодольск муниципаль районы” муниципаль берәмлегенә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр җирлекләре җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне тапшыру турындагы килешүләр төзү тәртибенә таянып, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре вәкиллекле органнарының (1 нче кушымта) «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында тәкъдимнәрен кабул итәргә (2 нче, 3 нче кушымта).

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре вәкаләтләрен Татарстан Республикасының «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлек тарафыннан кабул итәргә.

3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге

карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшырырга.

4. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләренең Башкарма комитетлары белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлдәге законнар нигезендә тапшыру турында килешүләр (4 нче, 5 нче кушымталар) төзергә.

5. Кабул ителгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар күләмнәре әлеге карарның 4 пунктында күрсәтелгән Килешүнең шартлары белән билгеләнә дип билгеләргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**

Зеленодольск муниципаль районы
Советы
2015 елның 15 декабрендәге 39
номерлы карарына
1 нче номерлы кушымта

Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен әлеге карар нигезендә тапшыручылар Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре
исемлеге

| №№ | Муниципаль берәмлек исеме |
|---|---|
| 1 | Васильево шәһәр тибындагы поселок |
| 2 | Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселок |
| 3 | Әйшә авыл җирлеге |
| 4 | Акъегет авыл җирлеге |
| 5 | Бишнә авыл җирлеге |
| 6 | Олы Ачасыр авыл җирлеге |
| 7 | Большие Ключи авыл җирлеге |
| 8 | Олы Карагужа авыл җирлеге |
| 9 | Олы Шырдан авыл җирлеге |
| 10 | Олы Җәке авыл җирлеге |
| 11 | Күгәй авыл җирлеге |
| 12 | Күгеш авыл җирлеге |
| 13 | Мамадыш-Әкил авыл җирлеге |
| 14 | Мулла Иле авыл җирлеге |
| 15 | Түбән Урысбага авыл җирлеге |
| 16 | Новопольский авыл җирлеге |
| 17 | Норлат авыл җирлеге |
| 18 | Октябрь авыл җирлеге |
| 19 | Осиново авыл җирлеге |
| 20 | Раифа авыл җирлеге |
| 21 | Рус Әҗиле авыл җирлеге |
| 22 | Зөя авыл җирлеге |
| 23 | Өтәшкә авыл җирлеге |

Зеленодольск муниципаль районы
Советы
2015 елның 15 декабрендәге 39
номерлы карарына
2 нче номерлы кушымта

Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге кабул итә торган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр тибындагы поселокларның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләр исемлеге

- халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру, җирлек китапханә фондларының сакланышын тәэмин итү һәм комплектлау;

-җирлек милкендә булган мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклап калу, куллану һәм популярлаштыру, җирлек территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклау;

- җирле традицион халык сәнгать иҗатын үстерү өчен шартлар тудыру, җирлектә халык сәнгать һөнәрләрен саклап калуда, торгызуда һәм үстерүдә катнашу;

- җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру.

Зеленодольск муниципаль районы
Советы
2015 елның 15 декабрендәге 39
номерлы карарына
3 нче номерлы кушымта

Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге кабул итә торган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр тибындагы поселокларның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләр исемлеге

- җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру.

Зеленодольск муниципаль районы
Советы
2015 елның 15 декабрендәге 39
номерлы карарына
4 нче номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының ________________«шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлешен тапшыру турында Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты һәм ____________ шәһәр җирлеге Башкарма комитеты арасында
Килешү

"______" ___________ 20____ел                    _________________

Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эш итүче, Егоров Сергей Геннадьевич җитәкчесе йөзендә, алга таба «Район Башкарма комитеты» дип аталучы, бер яктан һәм ________ шәһәр җирлегенең Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының _________ “шәһәр тибындагы поселок” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эш итүче, _________________________(Ф.И.О.) шәһәр җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе йөзендә алга таба «Җирлек Башкарма комитеты» дип аталучы, икенче яктан, «Яклар» дип аталучы, 2003 елның 06 октябендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» Федераль законның 15 статьяның 4 өлешенә, 52 статьяның 3 өлешенә таянып, түбәндәгеләр турында әлеге килешүне төзеделәр:

## 1. КИЛЕШҮ ПРЕДМЕТЫ

Әлеге Килешүнең предметы – Җирлек Башкарма комитет тарафыннан Район Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен башкаруны тапшыру тора:

- халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру, җирлек китапханә фондларының сакланышын тәэмин итү һәм комплектлау;

-җирлек милкендә булган мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклап калу, куллану һәм популярлаштыру, җирлек территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклау;

- җирле традицион халык сәнгать иҗатын үстерү өчен шартлар тудыру, җирлектә халык сәнгать һөнәрләрен саклап калуда, торгызуда һәм үстерүдә катнашу;

- җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру.

**2. Якларның хокуклары һәм бурычлары**

2.1. Җирлек Башкарма комитеты Районның Башкарма комитетына бурычлы:

әлеге Килешүнең 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар рәвешендә финанс чараларын бирергә (алга таба - тапшырылган вәкаләтләр);

тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны бирергә;

Район Башкарма комитеты тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда консультация һәм методик ярдәм күрсәтергә.

2.2. Җирлек Башкарма комитеты түбәндәгеләргә хокуклы:

Район Башкарма комитетының үзенә тапшырылган вәкаләтләрне үтәвен, шулай ук әлеге Килешүнең 3 пунктында күрсәтелгән бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны тикшереп торуны башкарырга. Кагыйдә бозулар ачыкланган очракта, Җирлек Башкарма комитеты Район Башкарма комитеты тарафыннан үтәлеше мәҗбүри булган очракта ачыкланган хокук бозуларны билгеле бер вакытта хәбәр итү вакытыннан ук бетерү өчен язма таләпләр җибәрергә хокуклы;

Район Башкарма комитетыннан тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру, шулай ук әлеге максатларга бирелгән финанс чараларны куллану белән бәйле кирәкле мәгълүмат, материаллар һәм документларны соратып алырга;

тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча Район Башкарма комитетына тәкъдимнәр кертергә.

2.3. Район Башкарма комитеты бурычлы:

закон таләпләре нигезендә тапшырылган вәкаләтләрнең тиешле дәрәҗәдә үтәлешен, шул исәптән Җирлек Башкарма комитеты тарафыннан бары тик тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны гамәлгә ашырырга (тәэмин итәргә);

тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлеше турында, вәкаләтләрне үтәү өчен бирелгән финанс чараларыннан файдалану, шулай ук әлеге Килешү предметына кагылышлы башка төрле рәсми мөрәҗәгатьләр буенча Җирлек Башкарма комитетына хисап бирергә;

Җирлек Башкарма комитет тарафыннан тәкъдим ителгән язма таләпләрне, тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча Район Башкарма комитеты тарафыннан ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында, бер айдан да соңга калмыйча (әгәр таләптә башка вакыт күрсәтелмәгән булса) хокук бозуларны бетерү буенча чаралар күрергә һәм бу хакта кичекмәстән Җирлек Башкарма комитетына хәбәр итәргә;

Килешү гамәле туктатылган очракта, файдаланылмаган финанс чараларын кире кайтарырга;

тапшырылган вәкаләтләрне тиешенчә үтәп булмаган очракта, вәкаләтләрне үтәп булмавы турында билгеле булганнан соң ун көн эчендә Җирлекнең Башкарма комитетына язма рәвештә хәбәр итәргә.

2.4. Районның Башкарма комитеты хокукка ия:

тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Җирлек Башкарма комитеты тарафыннан тапшырыла торган финанс чараларны алырга һәм кулланырга;

тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Җирлек Башкарма комитетыннан кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә матди ресурслардан һәм башка финанс чараларыннан законнар нигезендә файдаланырга;

тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән гамәлдәге законнарга каршы килмәгән теләсә нинди башка гамәлләрне гамәлгә ашырырга.

## 3. Бюджетара трансфертлар

3.1. Әлеге Килешү предметы буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы _______________ “шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге бюджетыннан бирелә торган Зеленодольск муниципаль районы бюджетына әлеге килешүнең аерылгысыз өлеше булган кушымта нигезендә, бюджет законнары нигезендә бюджетара трансфертлар исәбенә гамәлгә ашырыла.

3.2. Финанс чараларын Район Башкарма комитеты максатчан файдаланмаган очракта, алар Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының __________________ «шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге бюджетына, Җирлек Башкарма комитеты таләбе буенча ун көн эчендә кайтарылырга тиеш.

## 4. Вәкаләтләрнең үтәлешен тикшереп тору

4.1. Җирлек Башкарма комитеты тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерә, Район Башкарма комитетыннан тапшырылган финанс чараларыннан файдалану турында кирәкле мәгълүмат соратып ала. Район Башкарма комитеты Җирлек Башкарма комитетының дәлилләнгән мөрәҗәгате буенча соратып алына торган мәгълүматны бирергә һәм аның вәкилләренең тикшерелә торган объектларга керү мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

4.2. Хисапларның формасы һәм аларны бирү тәртибе Җирлек Башкарма комитетының хокукый актлары белән билгеләнә һәм Район Башкарма комитеты белән килештерелә.

4.1. Тапшырылган финанс чараларын тотуны тикшереп тору «Зеленодольск муниципаль районының контроль-хисап палатасы» муниципаль

учреждениесе, шул исәптән Җирлек Башкарма комитеты таләбе буенча гамәлгә ашырыла.

## 5. Килешүнең гамәлдә булу срогы

5.1. Әлеге Килешү 2016 елның «01» гыйнварыннан үз көченә керә һәм 2016 елның «31» декабрендә гамәлдә була.

5.2. Якларның берсе дә әлеге Килешүнең 5.1 пунктында каралган вакыт тәмамланырга 30 көннән дә соңга калмыйча аны өзү турында белдермәсә, Килешү киләсе елга озайтылган дип санала.

## 6. Нигезләмәләр һәм вакытыннан алда туктату тәртибе Килешүләр

6.1. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

Яклар килешүе буенча;

бер яклы тәртиптә түбәндәге очракта:

- Үз йөкләмәләрен Якларның берсенең үтәмәве яисә тиешенчә үтәмәве;

- Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарын һәм (яисә) Татарстан Республикасы законнарын үзгәрүе, нәтиҗәдә  Район Башкарма комитеты тарафыннан вәкаләтләрне үтәү мөмкин түгел, яисә килеп туган шартларда әлеге вәкаләтләр аеруча нәтиҗәле гамәлгә ашырылырга мөмкин.

6.2. Әлеге Килешүнең өзелүе турында хәбәрнамә башка Якка, аның гамәлдә булу вакыты тәмамланганчы 30 көннән дә соңга калмыйча, язма рәвештә җибәрелә.

6.3. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, Район Башкарма комитеты Җирлек Башкарма комитетына вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган файдаланылмаган финанс чараларын кире кайтара.

6.4. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы законнарда  каралган нигезләр буенча  да туктатыла.

## 7. Якларның җаваплылыгы

7.1. Әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү законнарда каралган җаваплылык барлыкка килүгә нигез булырга мөмкин.

7.2. Әлеге Килешү буенча Якларның берсе йөкләмәләрен үтәмәгән өчен гаепле Як әлеге Килешүгә кушымтада каралган финанс чаралары күләменең 0,1 проценты күләмендә штраф түли.

7.3. Штраф түләү Якларны әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне алга таба үтәүдән азат итми.

## 8. Бәхәсләрне хәл итү тәртибе

8.1 Әлеге Килешүнең үтәлеше белән бәйле бәхәсләр Яклар тарафыннан сөйләшүләр алып бару һәм башка килештерү процедураларын куллану юлы белән хәл ителә.

8.2. Бәхәсне сөйләшүләр алып бару һәм башка килештерү процедураларыннан файдалану юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул законнарда каралган башка тәртиптә карап тикшерелергә тиеш.

## 9. Йомгаклау нигезләмәләре

9.1. Әлеге Килешүгә кертелгән барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр Якларның үзара ризалыгы буенча кертелә һәм язма рәвештә өстәмә Килешү белән рәсмиләштерелә. Өстәмә килешүләр әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

9.2. Килешү ике нөсхәдә, бер үк юридик көчкә ия, һәр Як өчен берәр нөсхәдә төзелгән.

9.3. Әлеге Килешүгә кушымта итеп бирелә:

«Бюджетара трансфертлар күләме» кушымтасы

## 10. Якларның имзалары

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы<br>Зеленодольск муниципаль районы<br>Башкарма комитеты җитәкчесе | Татарстан Республикасы<br>Зеленодольск муниципаль районы<br>_____________ шәһәр җирлеге<br>Башкарма комитетының<br>Җитәкчесе |
| ___________________/<br>С.Г.Егоров/ | ___________/<br>_______________/ |
| "____" ____________20_ ел | "____"<br>_____________20___ел |

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «
шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлешен тапшыру турында Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты һәм шәһәр җирлеге Башкарма комитеты арасында Килешүгә
кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «___________шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар күләме

Әлеге Килешү предметы буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы ______________ “шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге бюджетыннан бирелә торган Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бюджетара трансфертлар исәбенә гамәлгә ашырыла. Тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар күләме___________ сум.

Зеленодольск муниципаль районы
Советы
2015 елның 15 декабрендәге 39
номерлы карарына
5 нче номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының ________________ “авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлешен тапшыру турында Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты һәм ____________ авыл җирлеге Башкарма комитеты арасында
Килешү

"____" __________ 20__ _ел                    ___________________

Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эш итүче, Егоров Сергей Геннадьевич житәкчесе йөзендә, алга таба «Район Башкарма комитеты» дип аталучы, бер яктан һәм ________ авыл җирлегенең Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының _________ “авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эш итүче, _________________________(Ф.И.О.) авыл җирлеге Башкарма комитеты Башлыгы йөзендә алга таба «Җирлек Башкарма комитеты» дип аталучы, икенче яктан, «Яклар» дип аталучы, 2003 елның 06 октябендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» Федераль законның 15 статьяның 4 өлешенә, 52 статьяның 3 өлешенә таянып, түбәндәгеләр турында әлеге килешүне төзеделәр:

## 1. КИЛЕШҮ ПРЕДМЕТЫ

Әлеге Килешүнең предметы - Җирлек Башкарма комитетыннан Район Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен башкаруны тапшыру:

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы _________ авыл җирлегендә яшәүчеләренә ял итүне оештыру һәм халыкны мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру.

## 2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Җирлек Башкарма комитеты Районның Башкарма комитетына бурычлы:

әлеге Килешүнең 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар рәвешендә финанс чараларын бирергә (алга таба - тапшырылган вәкаләтләр);

тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны бирергә;

Район Башкарма комитеты тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда консультация һәм методик ярдәм күрсәтергә.

2.2. Җирлек Башкарма комитеты түбәндәгеләргә хокуклы:

Район Башкарма комитетының үзенә тапшырылган вәкаләтләрне үтәвен, шулай ук әлеге Килешүнең 3 пунктында күрсәтелгән бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны тикшереп торуны башкарырга. Кагыйдә бозулар ачыкланган очракта, Җирлек Башкарма комитеты Район Башкарма комитеты тарафыннан үтәлеше мәҗбүри булган очракта ачыкланган хокук бозуларны билгеле бер вакытта хәбәр итү вакытыннан ук бетерү өчен язма таләпләр җибәрергә хокуклы;

Район Башкарма комитетыннан тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру, шулай ук әлеге максатларга бирелгән финанс чараларны куллану белән бәйле кирәкле мәгълүмат, материаллар һәм документларны соратып алырга;

тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча Район Башкарма комитетына тәкъдимнәр кертергә.

2.3. Район Башкарма комитеты бурычлы:

закон таләпләре нигезендә тапшырылган вәкаләтләрнең тиешле дәрәҗәдә үтәлешен, шул исәптән Җирлек Башкарма комитеты тарафыннан бары тик тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны гамәлгә ашырырга (тәэмин итәргә);

тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлеше турында, вәкаләтләрне үтәү өчен бирелгән финанс чараларыннан файдалану, шулай ук әлеге Килешү предметына кагылышлы башка төрле рәсми мөрәҗәгатьләр буенча Җирлек Башкарма комитетына хисап бирергә;

Җирлек Башкарма комитет тарафыннан тәкъдим ителгән язма таләпләрне, тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча Район Башкарма комитеты тарафыннан ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында, бер айдан да соңга калмыйча (әгәр таләптә башка вакыт күрсәтелмәгән булса) хокук бозуларны бетерү буенча чаралар күрергә һәм бу хакта кичекмәстән Җирлек Башкарма комитетына хәбәр итәргә;

Килешү гамәле туктатылган очракта, файдаланылмаган финанс чараларын кире кайтарырга;

тапшырылган вәкаләтләрне тиешенчә үтәп булмаган очракта, вәкаләтләрне үтәп булмавы турында билгеле булганнан соң ун көн эчендә Җирлекнең Башкарма комитетына язма рәвештә хәбәр итәргә.

2.4. Районның Башкарма комитеты хокукка ия:

тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Җирлек Башкарма комитеты тарафыннан тапшырыла торган финанс чараларны алырга һәм кулланырга;

тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Җирлек Башкарма

комитетыннан кирәкле мәгълүматны  соратып алырга;

тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә матди ресурслардан һәм башка финанс чараларыннан законнар нигезендә файдаланырга;

тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән гамәлдәге законнарга каршы килмәгән теләсә нинди башка гамәлләрне гамәлгә ашырырга.

## 3. Бюджетара трансфертлар

3.1. Әлеге Килешү предметы буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы “______________авыл җирлеге ” муниципаль берәмлеге бюджетыннан бирелә торган Зеленодольск муниципаль районы бюджетына әлеге килешүнең аерылгысыз өлеше булган кушымта нигезендә, бюджет законнары нигезендә бюджетара трансфертлар исәбенә гамәлгә ашырыла.

3.2. Финанс чараларын Район Башкарма комитеты максатчан файдаланмаган очракта, алар Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының “_________________ авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге бюджетына, Җирлек Башкарма комитеты таләбе буенча ун көн эчендә кайтарылырга тиеш.

## 4. Вәкаләтләрнең үтәлешен тикшереп тору

4.1. Җирлек Башкарма комитеты тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерә, Район Башкарма комитетыннан тапшырылган финанс чараларыннан файдалану турында кирәкле мәгълүмат соратып ала. Район Башкарма комитеты Җирлек  Башкарма комитетының дәлилләнгән мөрәҗәгате  буенча соратып алына торган мәгълүматны бирергә һәм аның вәкилләренең тикшерелә торган объектларга керү мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

4.2.  Хисапларның формасы һәм аларны бирү тәртибе Җирлек Башкарма комитетының хокукый актлары белән билгеләнә һәм Район Башкарма комитеты белән килештерелә.

4.1. Тапшырылган финанс чараларын тотуны тикшереп тору «Зеленодольск муниципаль районының контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесе, шул исәптән Җирлек Башкарма комитеты таләбе буенча гамәлгә ашырыла.

## 5. Килешүнең гамәлдә булу срогы

5.1. Әлеге Килешү 2016 елның «01» гыйнварыннан үз көченә керә һәм 2016 елның «31» декабрендә гамәлдә була.

5.2. Якларның берсе дә әлеге Килешүнең 5.1 пунктында каралган вакыт тәмамланырга 30 көннән дә соңга калмыйча аны өзү турында белдермәсә, Килешү киләсе елга озайтылган дип санала.

## 6. Нигезләмәләр һәм вакытыннан алда туктату тәртибе Килешүләр

6.1. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

Яклар килешүе буенча;

бер яклы тәртиптә түбәндәге очракта:

- Үз йөкләмәләрен Якларның берсенең үтәмәве яисә тиешенчә үтәмәве;
- Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарын һәм (яисә) Татарстан Республикасы законнарын үзгәрүе, нәтиҗәдә Район Башкарма комитеты тарафыннан вәкаләтләрне үтәү мөмкин түгел, яисә килеп туган шартларда әлеге вәкаләтләр аеруча нәтиҗәле гамәлгә ашырылырга мөмкин.

6.2. Әлеге Килешүнең өзелүе турында хәбәрнамә башка Якка, аның гамәлдә булу вакыты тәмамланганчы 30 көннән дә соңга калмыйча, язма рәвештә җибәрелә.

6.3. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, Район Башкарма комитеты Җирлек Башкарма комитетына вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган файдаланылмаган финанс чараларын кире кайтара.

6.4. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы законнарда каралган нигезләр буенча да туктатыла.

## 7. Якларның җаваплылыгы

7.1. Әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү законнарда каралган җаваплылык барлыкка килүгә нигез булырга мөмкин.

7.2. Әлеге Килешү буенча Якларның берсе йөкләмәләрен үтәмәгән өчен гаепле Як әлеге Килешүгә кушымтада каралган финанс чаралары күләменең 0,1 проценты күләмендә штраф түли.

7.3. Штраф түләү Якларны әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне алга таба үтәүдән азат итми.

## 8. Бәхәсләрне хәл итү тәртибе

8.1 Әлеге Килешүнең үтәлеше белән бәйле бәхәсләр Яклар тарафыннан сөйләшүләр алып бару һәм башка килештерү процедураларын куллану юлы белән хәл ителә.

8.2. Бәхәсне сөйләшүләр алып бару һәм башка килештерү процедураларыннан файдалану юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул законнарда каралган башка тәртиптә карап тикшерелергә тиеш.

## 9. Йомгаклау нигезләмәләре

9.1. Әлеге Килешүгә кертелгән барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр Якларның үзара ризалыгы буенча кертелә һәм язма рәвештә өстәмә Килешү белән рәсмиләштерелә. Өстәмә килешүләр әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

9.2. Килешү ике нөсхәдә, бер үк юридик көчкә ия, һәр Як өчен берәр нөсхәдә төзелгән.

9.3. Әлеге Килешүгә кушымта итеп бирелә:

«Бюджетара трансфертлар күләме» кушымтасы

## 10. Якларның имзалары

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы<br>Зеленодольск муниципаль районы<br>Башкарма комитеты Җитәкчесе | Татарстан Республикасы<br>Зеленодольск муниципаль районы<br>_____________ авыл җирлеге<br>Башлыгы |
| ___________________/<br>С.Г.Егоров/ | ___________/<br>_______________/ |
| "____" ____________20__ел | "____"<br>_____________20___ел |

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының “________________авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлешен тапшыру турында Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты һәм _________ авыл җирлеге Башкарма

комитеты арасында Кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының
«___________авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле
әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча тапшырыла торган
вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле
бюджетара трансфертлар күләме

Әлеге Килешү предметы буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы “______________ авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге бюджетыннан бирелә торган Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бюджетара трансфертлар исәбенә гамәлгә ашырыла. Тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар күләме_______ сум.